# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлегенең Таш-Елга торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы**

12 ноябрь 2025 ел.

№ 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 20.03.2025 ел № 33-ФЗ Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 12 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2026 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлеге Таш-Елга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мен) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500,00 (биш йоз ) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы»:

1. **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту**:

- Урманлы урамы буенча җәйге юлларны грейдировкалау килешүе буенча хезмәтләр өчен түләү;
- Урманлы урамы буенча юлларны кышкы тотуга килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;
- юл буендагы улэннэрне чабу
- ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, тракторчы хезмәте өчен түләү

2. **су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау:**

- су белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау,материаллар,насос сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү;
- су башнясын ремонтлау, эш өчен килешү буенча түләү
- полиэтилен торба сатып алу;

3. **урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

- Таш-Елга авылының урам челтәрләренә техник хезмәт күрсәтүгә килешү буенча түләү;
- светодиодлы лампалар сатып алу;
- Таш-Елга авылының урам тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау.

**4. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**

- янгын сундерү машинасын карап торган очен килешу буенча тулэу.
- янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу.

**5. торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү::**

- үләннәрне чабу;
- тозелеш материаллары сатып алу,паркны төзекләндерү.

**6. Ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү:**

- Таш-Елга авылы зиратында үләннәрне чабу;
- каты коммуналь калдыкларын чыгару;

**7. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү:**

- Таш-Елга авылының Тонтак чишмәсен ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 48 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 28 кеше, бу 58% тәшкил итә.Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен 30 граждан җыенда катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Керәш-Шуран авыл җирлегендә Таш-Елга авылы гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2026 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлегенең Таш-Елга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000,00 (бер мең ) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә, түбәндәге категория гражданнар: 1 һәм 2 төркем инвалидлар, көндезге бүлектә укучы студентлар өчен 500,00 (бишйөз) сум күләме билгеләргә, локаль конфликтларга һәм Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, шулай ук тормыш иптәшен (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаганда әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтергә:

**1. торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту**:

- Урманлы урамы буенча җәйге юлларны грейдировкалау килешүе буенча хезмәтләр өчен түләү;
- Урманлы урамы буенча юлларны кышкы тотуга килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;
- юл буендагы улэннэрне чабу
- ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, тракторчы хезмәтләре өчен түләү

2. **су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын,скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

- су белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау,
- материаллар,насос сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү;
- су башнясын ремонтлау, эш өчен килешү буенча түләү.
- полиэтилен торба сатып алу;

3. **урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

- Таш-Елга авылының урам челтәрләренә техник хезмәт күрсәтүгә килешү буенча түләү;
- светодиодлы лампалар сатып алу;
- Таш-Елга авылының урам тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау.

4. **беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**

- янгын сундерү машинасын карап торган очен килешу буенча тулэу;
- янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу;

5. **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү::**

- үләннәрне чабу;
- тозелеш материаллары сатып алу,паркны төзекләндерү.

6. **ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү:**

- Таш-Елга авылы зиратында үләннәрне чабу;
- каты коммуналь калдыкларын чыгару;

7. **Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү:**

- Таш-Елга авылының Тонтак чишмәсен ремонтлау

4. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Таш-Елга авылы Урманлы урамы 31 йортында , Мөслим муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://muslumovo.tatarstan.ru. һәм ТР Хокукый мәгълүматның рәсми порталында.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Керәш-Шуран авыл җирлеге башлыгы ______________ Р.Г.Сафиуллин